**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 июль № 549

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1078 нче, 2014 ел, 22 февраль, 109 нчы, 2014 ел, 24 февраль, 118 нче, 2014 ел, 30 апрель, 284 нче, 2014 ел, 2 июнь, 374 нче, 2014 ел, 17 июнь, 418 нче, 2014 ел, 8 июль, 473 нче, 2014 ел, 9 июль, 477 нче, 2014 ел, 25 август, 612 нче, 2014 ел, 1 октябрь, 709 нчы, 2014 ел, 24 ноябрь, 901 нче, 2014 ел, 6 декабрь, 956 нчы, 2014 ел, 31 декабрь, 1083 нче, 2015 ел, 1 июнь, 390 нчы, 2015 ел, 24 июнь, 459 нчы, 2015 ел, 25 июнь, 460 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:
«Программаның бурычлары» юлына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерының (алга таба – Кластер) конкурентлылык сәләтен дөньякүләм дәрәҗәгә кадәр күтәрүне тәэмин иткән шартлар тудыру»;

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. 2015 – 2018 елларга Кластер үсеше»;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>
Программаны финанслауның гомуми күләме 13 456 751,132 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 7 087 037,79 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 5 367 536,682 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган җирле бюджетлар акчасы исәбеннән – 400,0 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән –1 001 776,66 мең сум:
<table>
<tr><th rowspan="3">Ел</th><th rowspan="3">Программа буенча барысы</th><th colspan="4">Акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th rowspan="2">Татарстан Республи-касы бюджеты</th><th colspan="3">җәлеп итергә планлаштырылган акча</th></tr>
<tr><th>федераль бюджет</th><th>җирле бюджет</th><th>бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>3 746007,57</td><td>1 812 934,84</td><td>1 776 653,73**</td><td>100,0</td><td>156 319,0</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>5 221 657,962</td><td>1 550 749,2</td><td>2 998 201,102***</td><td>150,0</td><td>672 557,66</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>1 711 322,7</td><td>1 318 140,35</td><td>220 132,35*</td><td>150,0</td><td>172 900,0</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>813473,1</td><td>627 329,6</td><td>186 143,5*</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>792 524,6</td><td>606 118,6</td><td>186 406,0*</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>585 882,6</td><td>585 882,6</td><td>*</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>585 882,6</td><td>585 882,6</td><td>*</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>Бар-лыгы</td><td>13 456 751,132</td><td>7 087 037,79</td><td>5 367 536,682</td><td>400,0</td><td>1 001 776,66</td></tr>
</table>
Искәрмә: Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>
*Федераль бюджет акчасы исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын
</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнәчәк.<br>** Шул исәптән 194 004,37 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2014 елда үзләштерелгән акчасы.<br>*** Шул исәптән 437 495,32 мең сум – «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2014 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2015 елда үзләштерергә планлаштырыла торган акчасы»; |

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«инновацион эшчәнлек белән идарә итү өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча, шулай ук ярдәмче программаны тормышка ашыру юнәлешләре буенча һөнәри яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү үткән Кластер хезмәткәрләре санын 150 кешедән ким булмаган санда саклау;

Кластерның ике яки күбрәк оешмасы яисә Кластерның катнашучысы булган бер яки берничә оешма чит ил оешмалары белән берлектә башкарган фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр тармагында эшләр һәм проектлар күләмен ел саен 5 процентка кадәр арттыру»;

Программаның II бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«5. Кластерның дөньякүләм дәрәҗәдә конкурентлылык сәләтен күтәрүне тәэмин иткән шартлар тудыру.»;

түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә:

«5). 2015 – 2018 елларга Кластерны үстерү.»;

түбәндәге эчтәлекле егерме беренче – егерме икенче абзацлар өстәргә:

«инновацион эшчәнлек белән идарә итү өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча, шулай ук ярдәмче программаны тормышка ашыру юнәлешләре буенча һөнәри яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү үткән Кластер хезмәткәрләре санын 150 кешедән ким булмаган санда саклау;

Кластерның ике яки күбрәк оешмасы яисә Кластерның катнашучысы булган бер яки берничә оешма чит ил оешмалары белән берлектә башкарган фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр тармагында эшләр һәм проектлар күләмен ел саен 5 процентка кадәр арттыру.»;

түбәндәге эчтәлекле утыз алтынчы – кырык беренче абзацлар өстәргә:

«Кластерның дөньякүләм дәрәҗәдә конкурентлылык сәләтен күтәрүне тәэмин

иткән шартлар тудыруга түбәндәгеләр буенча чаралар юнәлдерелә:

Кластерның катнашучысы булган ике яки күбрәк оешма бергәләп башкарган территориаль кластерны үстерү проектларын эшләүгә һәм тормышка ашыруга булышлык итүгә;

Кластерның катнашучысы булган оешмалар мәнфәгатьләрендә кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү, квалификация күтәрү һәм стажировкалауны, консультация хезмәтләре күрсәтүне оештыруга;

катнашучы оешмаларга яңа продуктларны (хезмәтләрне) базарга чыгаруда, фән-техника тармагында Кластерның катнашучысы булган оешмаларның, шул исәптән чит ил оешмалары белән кооперациясен үстерүдә булышлык күрсәтүгә;

Кластер урнашкан территорияләрдә инновацион, мәгариф, транспорт, энергетика, инженер, экология һәм социаль инфраструктура объектларын үстерүгә;

Кластерның махсуслашкан оешмасы – «Кама инновацион территориаль-җитештерү кластеры» коммерциячел булмаган партнерлык»ның агымдагы эшчәнлеген тәэмин итүгә.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 13 456 751,132 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 7 087 037,79 мең сум; җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 5 367 536,682 мең сум; җәлеп итәргә планлаштырыла торган җирле бюджетлар акчасы исәбеннән – 400,0 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән –1 001 776,66 мең сум:

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча | | |
| | | федераль бюджет | җирле бюджет | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 1 812 934,84 | 1 776 653,73** | 100,0 | 156 319,0 |
| 2015 | 1 550 749,2 | 2 998 201,102*** | 150,0 | 672 557,66 |
| 2016 | 1 318 140,35 | 220 132,35* | 150,0 | 172 900,0 |
| 2017 | 627 329,6 | 186 143,5* | 0,0 | 0,0 |
| 2018 | 606 118,6 | 186 406,0* | 0,0 | 0,0 |
| 2019 | 585 882,6 | * | 0,0 | 0,0 |
| 2020 | 585 882,6 | * | 0,0 | 0,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Барлы-гы | 7 087 037,79 | 5 367 536,682 | 400,0 | 1 001 776,66 |

Искәрмә: Финанслау күләмнәре фаразлау характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

* Федераль бюджет акчасы исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнә.

******Шул исәптән 194 004,37 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2011 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2014 елда үзләштерелгән акчасы.

*** Шул исәптән 437 495,32 мең сум – «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2014 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2015 елда үзләштерергә планлаштырыла торган акчасы»;

Программаның V бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кластерның дөньякүләм дәрәҗәдә конкурентлылык сәләтен күтәрүне тәэмин иткән шартлар тудыру.»;

Программага 1 нче кушымтаның таблицасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Кластерның дөньякүләм дәрәҗәдә конкурентлылык сәләтен күтәрүне тәэмин иткән шартлар тудыру | Инновацион эшчәнлек белән идарә итү өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча, шулай ук ярдәмче программаны тормышка ашыру юнәлешләре буенча һөнәри яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү үткән Кластер хезмәткәрләре саны, кеше | 0 | 0 | 150 | 150 | 150 | 150 | - | - |
| | | Кластерның ике яки күбрәк оешмасы яисә Кластерның катнашучысы булган бер яки берничә оешма чит ил оешмалары белән берлектә башкарган фәнни тикшеренүләр һәм | 0 | 0 | 5 | 5 | 5 | 5 | - | -»; |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | эшләнмәләр тармагында эшләр һәм проектлар күләме арту, кыйммәти чагылышта (узган елга карата мөнәсәбәттә, процент) | | | | | | | | |

Программага 2 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымтага туры килгән редакциядә бәян итәргә;

«2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасында:

Ярдәмче программа паспортындагы «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм җәлеп итәргә планлаштырыла торган чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>
Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 5 673 888,867 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 664 098,873 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 4 009 789,994 мең сум:<br><br>
(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</th><th>Барысы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>707 864,293</td><td>1 694 793,532 **</td><td>2 402 657,825 **</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>456 234,58</td><td>2 314 996,462 ***</td><td>2 771 231,042 ***</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>500 000,0</td><td>*</td><td>500 000,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1 664 098,873</td><td>4 009 789,994</td><td>5 673 888,867</td></tr>
</table>
Искәрмә: Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>
* Федераль бюджет акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме федераль бюджеттан кече һәм урта эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме күрсәтүгә субсидия бирү йомгаклары буенча ел саен билгеләнә.<br>
**Шул исәптән 194 004,37 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2014 елда үзләштерелгән акчасы»;
</td>
</tr>
</table>

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 5 673 888,867 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 664 098,873 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 4 009 789,994 мең сум:

(мең сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | Барысы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 707 864,293 | 1 694 793,532 ** | 2 402 657,825 ** |
| 2015 | 456 234,58 | 2 314 996,462 *** | 2 771 231,042 *** |
| 2016 | 500 000,0 | * | 500 000,0 |
| Барлыгы | 1 664 098,873 | 4 009 789,994 | 5 673 888,867 |

Искәрмә: Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

* Федераль бюджет акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме федераль бюджеттан кече һәм урта эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме күрсәтүгә субсидия бирү йомгаклары буенча ел саен билгеләнә.

**Шул исәптән 194 004,37 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2014 елда үзләштерелгән акчасы.

***Шул исәптән 437 495,32 мең сум – «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2014 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2015 елда үзләштерергә планлаштырыла торган акчасы»;

ярдәмче программага кушымтаның таблицасында:

8 пунктның 10 графасында «40 000,0» саннарын «19 855,628» саннарына алмаштырырга;

23 пунктның 10 графасында «23 621,048» саннарын «0,0» саннарына алмаштырырга;

Программага бу карарга теркәлгән 2 нче кушымта нигезендәге редакциядә бәян итеп, «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасын өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидия алу өчен Татарстан Республикасыннан гомуми гаризага кертелергә тиешле чараларны сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 4 сентябрь, 630 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидия алу өчен Татарстан Республикасыннан гомуми гаризага кертелергә тиешле чараларны сайлап алу тәртибен раслау турында»;

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчен югалаткан дип тану турында» 2015 ел, 30 июнь, 659 нчы карары белән расланган инновацион территориаль кластерларны үстерү буенча комплекслы инвестицион проектларны тормышка ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләре нигезендә (алга таба – Кагыйдәләр), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасын раслау турында” 2013 ел, 3 сентябрь, 624 нче карары белән расланган 2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы» сүзләрен «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән карар белән расланган 2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидия алу өчен Татарстан Республикасыннан гомуми гаризага кертелергә тиешле чараларны сайлап алу тәртибендә:

исемендә «2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы» сүзләрен «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчен югалаткан дип тану турында» 2015 ел, 30 июнь, 659 нчы карары белән расланган инновацион территориаль кластерларны үстерү буенча комплекслы инвестицион проектларны тормышка ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә

эшләнде.»;

Тәртипнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасын раслау турында” 2013 ел, 3 сентябрь, 624 нче карары белән расланган 2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы (алга таба – Программа)» сүзләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының (алга таба – Программа) «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект» сүзләренә алмаштырырга;»;

текст буенча «Программа» сүзен тиешле килештәге «Ярдәмче программа» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымтаны әлеге карарга 3 нче кушымтага туры килгән редакциядә бәян итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-житештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы чараларын тормышка ашыру өчен гариза бирүче оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1042 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының (алга таба – Программа) «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект чараларын тормышка ашыру өчен гариза бирүче оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче һәм «2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-житештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидия алуга Татарстан Республикасыннан уртак гаризага кертелергә тиешле чаралар сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 4 сентябрь, 630 нчы карарларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

карарның 1 пунктында «2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-житештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы» сүзләрен «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион

территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект» сүзләренә алмаштырырга;

карарның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

күрсәтелгән карар белән расланган 2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-житештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы чараларын тормышка ашыру өчен гариза бирүче оешмаларга субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-житештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы» сүзләрен «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының (алга таба – Программа) «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект чараларын тормышка ашыру өчен гариза бирүче оешмаларга субсидияләр бирү кагыйдәләрен билгели. Тәртип «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчен югалткан дип тану турында» 2015 ел, 30 июнь, 659 нчы карары (алга таба - Кагыйдәләр), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче һәм «2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-житештерү кластерына булышлык күрсәтү программасы чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидия алуга Татарстан Республикасыннан уртак гаризага кертелергә тиешле чаралар сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 4 сентябрь, 630 нчы карарлары (алга таба – Сайлап алу тәртибе) нигезендә эшләнде.»;

Тәртипнең 2 пунктында:

беренче абзацта «Программа» сүзен «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Кама инновацион территориаль-житештерү кластеры» пилот инновацион территориаль кластерын үстерү программасы» сүзләрен «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү

кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасын раслау турында» 2013 ел, 3 сентябрь, 624 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасын раслау турында» 2013 ел, 3 сентябрь, 624 нче карары белән расланган 2013-2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 21 сентябрь, 673 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасын раслау турында» 2013 ел, 3 сентябрь, 624 нче карары белән расланган 2013 – 2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 7 февраль, 74 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасын раслау турында» 2013 ел, 3 сентябрь, 624 нче карары белән расланган 2013 – 2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 8 сентябрь, 655 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасын раслау турында» 2013 ел, 3 сентябрь, 624 нче карары белән расланган 2013 – 2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 10 октябрь, 750 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 - 2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасын раслау турында» 2013 ел, 3 сентябрь, 624 нче карары белән расланган 2013 - 2016 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына булышлык күрсәтү программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 21 апрель, 273 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков